ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**28.02.2022** **г.Чистополь** **№ 144**

Чистай муниципаль районы буенча
2022 елның I кварталына торакның
1 квадрат метр гомуми мәйданының
нормативы турында

«2020-2025 елларга Чистай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе һәм торак урынның гомуми мәйданының Россия Федерациясе субъектлары буенча 2022 елның I кварталына бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы боерыгы, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 07 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» НП хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы буенча 2022 елның I кварталына торакның 1 квадрат метр (сумнарда) гомуми мәйданының нормативын 61 796 (алтмыш бер мең җиде йөз туксан алты) сум күләмендә расларга.
2. «Чистай муниципаль районы буенча 2022 елның I кварталына торакның 1 квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе турында» 2022 елның 25 гыйнварындагы 32 номерлы карар үз көчен югалткан дип танырга.
3. Чистай шәһәре Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов